**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур.,1А

**СОВЕТ АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Айбаш, ул.Центральная, 1А

Тел./факс: +7(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**26 апрель 2018 ел** **№ 114**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 66 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ, «Конкуренцияне яклау турында» 26.07.2006 ел, № 135-ФЗ, Айбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 66 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә, шулай ук күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару һәм 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законда каралган күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр бирү нигезендә күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, мондый исәпкә алынырга тиешле күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастр исәбен алып бару турында " 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә башкарыла.»;

1.2. 12 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2. Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә шартнамәләрен, хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән муниципаль милекне ияләү һәм (яки) файдалану хокукын күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү «Көндәшлекне яклау турында» 26.07.2006 ел, № 135-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар халыкка рәсми рәвештә җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Р. Сафиуллин